РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

03.09.2020 № 1226-п

Саба муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларын кайнар ризык белән тәэмин итү турында

Укучыларны кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру, балаларга социаль ярдәм күрсәтү һәм аларның сәламәтлеген ныгыту, белем бирү процессының уңайлы мохитен булдыру максатларында, Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларын кайнар ризык белән тәэмин итү турындагы Нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы муниципаль берәмлеге бюджетыннан муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләренә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының җыелма бюджет язмасы кысаларында әлеге максатларга 2020 елда каралган акчалар чикләрендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә укучыларның туклануын оештыруны тәэмин итү буенча вәкаләтле органы итеп “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе” МКУен билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләре Җитәкчеләренә:

3.1. гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны ике тапкыр кайнар ризык белән тәэмин итүне оештырырга;

3.2. укучыларны кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыруны бер укучыга туклану бәясеннән чыгып башкарырга кирәк;

4. Әлеге карарның гамәлдә булуын 2020 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратырга.

5. Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында

бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе” МКУ начальнигы И.Ф. Шакировка йөкләргә.

Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе М. Р. Ишниязов

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының
______________________
______________________
номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

**Саба муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларын кайнар ризык белән тәэмин итү турында Нигезләмә**

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Әлеге Нигезләмә укучыларның туклануын оештыру һәм финанс ягыннан тәэмин итү тәртибен, туклануны оештыру процессында катнашучыларның хокукларын һәм бурычларын, шулай ук Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы һәм Байлар Сабасы ш.т. б. гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыруны тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибен билгели.

1.2. Нигезләмә укучыларны кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру, балаларга социаль ярдәм күрсәтү һәм аларның сәламәтлеген ныгыту, белем бирү процессының уңайлы мохитен булдыру максатларында эшләнгән.

1.3. Укучыларны тукландыруны оештыру Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районының норматив хокукый актлары, Федераль санитар кагыйдәләр һәм нормалар, шулай ук әлеге Нигезләмә нигезендә гамәлгә ашырыла.

1.4. Гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру, кергән бюджет акчаларын һәм ата-аналар түләвен исәпкә алу һәм контрольдә тоту өчен җаваплылык учреждение җитәкчесенә йөкләнә.

1.5. Гомуми белем бирү оешмаларында туклануга бюджет акчаларын максатчан файдалануны “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе” Муниципаль казна учреждениесе контрольдә тота.

## 2. ТУКЛАНУНЫ ОЕШТЫРУ ТӘРТИБЕ

2.1. Туклануны оештыру буенча хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы яки белем бирү учреждениеләре тарафыннан азык-төлек продуктлары белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр арасындагы мөнәсәбәтләр гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә төзелгән контракт (шартнамә) белән җайга салына. Мәгариф оешмалары өчен азык-төлек

продуктларын сатып алу “Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар сатып алу, эшләр эшләү, хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә контракт системасы турында”гы 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.2. Туклануны оештыручы мәктәп ашханәсе түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

– квалификацияле кадрлар булу (раслаучы документлар булырга тиеш);
– һәр хезмәткәрнең шәхси медицина кенәгәсе булу;
– персоналның 2 елга бер тапкырдан да ким булмаган күләмдә гигиеник белем бирү программасы буенча гигиеник әзерлеген һәм яңадан укуын оештыру;
– продукциягә, тиешле кирәкле документлар белән, продуктның сыйфатын һәм куркынычсызлыгын раслаучы документлар булу;
– ашамлыкка технологик карталар булу;
– санитар-эпидемиологик таләпләргә һәм нормаларга туры килә торган, директор тарафыннан расланган, башкарма хакимиятнең дәүләт санитар-эпидемиологик күзәтчелекне гамәлгә ашыру өчен вәкаләтле территориаль органы белән килештерелгән баланслы туклану (шул исәптән хәрби җыеннар), һәм унике көнлек перспективалы кайнар ризык менюсы булу;
– тиешле документлар буенча авыл хуҗалыгы хайваннары, кош-корт, балык ите сатып алу, саклау һәм әзерләү өчен, балыклы һәм итле ризыклар әзерләү өчен ветеринария таныклыгы булу;
– кергән чималның, ярымфабрикатларның сыйфатын раслый торган документлар (ярашлылык сертификатлары, продукция җитештерү һәм сату сроклары, сертификатлар турында белешмәләр күрсәтелгән накладнойлар);
– фикерләр һәм тәкъдимнәр китабы;
– башкаручы турында мәгълүмат.

2.3. Көнгә бер укучыга туклану нормалары, Россия Федерациясе баш дәүләт санитар табибының 2008 елның 23 июлендәге 45 номерлы карары белән расланган, гомуми белем бирү оешмаларында, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә укучыларның туклануын оештыруга карата санитар-эпидемиологик таләпләр нигезендә расланган (СанПин 2.4.5.540908).

2.4. Продукция җитештергәндә туклануны оештыручы азык-төлек блогы хезмәткәрләре чималны салкын һәм җылылык белән эшкәртүнең гамәлдәге нормалар һәм кагыйдәләр белән билгеләнгән технологик режимын үтәргә тиеш.

2.5. Мәктәп ашханәсе эшен мәктәп администрациясе һәм укучыларның туклануын оештыруны тикшерү буенча җәмәгать комиссиясе контрольдә тота. Әзер продукциянең бракеражы, составына производство мөдире, медицина хезмәткәре, директор боерыгы белән билгеләнгән гомуми белем бирү учреждениесендә туклануны оештыру өчен җаваплы зат кергән бракераж комиссиясе тарафыннан төшерелә.

Укучыларны тукландыруны оештыруны контрольдә тоту буенча җәмәгать комиссиясе мәктәп администрациясе, педагогик хезмәткәрләр, медицина хезмәткәрләре, укучылар һәм ата-аналар арасыннан, мәктәп директоры боерыгы белән, кадрлар ротациясе принцибын үтәп оештырыла. Боерык күчермәсе

ашханә администрациясенә тапшырыла. Укучыларның туклануын оештыруны контрольдә тоту буенча иҗтимагый комиссия (кварталга кимендә 1 тапкыр), кушылган йөкләмәләрне үтәү һәм контрольдә тоту буенча эш турында, директор каршында киңәшмәдә, инструктив-методик киңәшмәләрдә, педагогик советта хисап тота.

2.6. Азык әзерләү технологиясен тикшерү көн саен производство мөдире, медицина хезмәткәре, директор боерыгы белән туклануны оештыру өчен җаваплы итеп билгеләнгән зат тарафыннан башкарыла, бу хакта бракераж журналында билге ясала.

2.7. Туклану өчен түләү муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының шәхси счетларына банклар аша акча түләнми торган исәп-хисап буенча башкарыла.

2.8. Җитәкче боерыгы белән мәгариф учреждениесе хезмәткәрләре арасыннан туклануны оештыру өчен җаваплы зат билгеләнә.

2.9. Гомуми белем бирү учреждениесендә укучыларны ашату дәресләр булган көннәрдә башкарыла. Ризык кабул итү режимы мәгариф учреждениесе директоры тарафыннан раслана һәм танышу өчен уңайлы урында урнаштырыла.

2.10. Һәр сыйныф укучылары өчен кайнар ризык сыйныф җитәкчесе тарафыннан алдан (1 көн эчендә) игълан ителгән укучылар саны нигезендә бирелә. Гариза төзегәндә сыйныф җитәкчесе ата-аналар (законлы вәкилләр) тарафыннан хәбәр ителгән дәрес калдырырга мөмкин булган балалар санын исәпкә ала.

2.11. Кайнар ризык бирүне финанс ягыннан тәэмин итү түбәндәгеләр хисабына гамәлгә ашырыла:

2.11.1 ата-аналар акчасы;

2.11.2 муниципаль бюджет акчалары;

2.11.3 авыл мәктәпләренең мәктәп яны участогында яшелчә үстерүдән кергән табыш.

2.12. Җирле бюджет акчалары хисабына түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

– Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе белән билгеләнгән күләмнәрдә укучыларның туклану бәясенең уку елы дәвамында көн саен кыйммәтләнүенә өлешчә компенсация;

– “Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында” 1998 елның 28 мартындагы 53 номерлы Федераль закон һәм Саба муниципаль районы Башкарма комитеты карары нигезендә, 10 нчы сыйныфта укучы ир-егетләрне укыту-кыр җыеннарында ашатуга акча бүлеп бирү.

## 3. УКУЧЫЛАРГА КАЙНАР РИЗЫК БИРҮ ТӘРТИБЕ

3.1. Укучыларга ризык бары тик ирекле рәвештә әти-әниләрнең (законлы вәкилләрнең) гаризасы нигезендә генә бирелә. Гаризада кайнар ризык бирү һәм аның төрләренең (иртәнге һәм (яки) төшке аш) саны билгеләнә. Кайнар ризык белән тәэмин итү, дәүләт санитария-эпидемиология күзәтчелеген гамәлгә ашырырга вәкаләтле башкарма хакимиятнең территориаль органы тарафыннан

килештерелгән якынча меню буенча, көнгә бер балага туклану нормасыннан чыгып гамәлгә ашырыла. Кайнар ризык бәясе нормасы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыруга карата санитар-эпидемиологик таләпләр нигезендә, азык-төлек продуктларының расланган нормалары буенча исәпләнә.

3.2. Укучыларга кайнар ризык бирү, сыйныфлар буенча, озынлыгы 20 минуттан да ким булмаган тәнәфесләрдә оештырыла. Һәр сыйныфка билгеле бер төшке аш өстәле беркетелә.

Учреждение укучылары директор раслаган график буенча туклана. Укучыларның азык-төлек блогына йөрүен, җибәрелгән иртәнге һәм төшке ашларның санын сыйныф җитәкчесе контрольдә тота. Азык-төлек блогының эш режимы учреждениенең эш режимына туры килә һәм атнага 6 көн тәшкил итә.

3.3. Укучыларны кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру өстәлләрне алдан ябу юлы белән башкарыла, кайнар ашларны чыгару кыңгырау шалтырарга 7-10 минут кала башкарыла.

3.4. Әгәр бала җитди сәбәпләр аркасында, аның өчен ата-аналары (законлы вәкилләре) түләгән кайнар ризыкны ашый алмаса, факт буенча файдаланылмаган финанс чаралары киләсе айга укучының туклану бәясе исәбенә бара.

## 3. УКУЧЫЛАРНЫҢ ТУКЛАНУЫН ОЕШТЫРУ ПРОЦЕССЫНДА КАТНАШУЧЫЛАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫН ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫН БҮЛҮ

4.1. Укучыларны тукландыруны оештыру, бу максатларга бюджет акчаларын тоту, сәүдә - җитештерү эшчәнлеге кагыйдәләрен, санитария-гигиена таләпләрен үтәү өчен җаваплылык, белем бирү оешмасы директорына, директор тарафыннан туклануны оештыру өчен җаваплы итеп билгеләнгән затка, мәгариф оешмасына беркетелгән медицина хезмәткәренә һәм белем бирү оешмасы ашханәсенең мөдиренә йөкләнә.

4.2. Мәгариф учреждениесе директоры:

– Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы норматив актлары, Федераль санитар кагыйдәләр һәм нормалар, мәктәп Уставы һәм әлеге Нигезләмә нигезендә укучыларны тукландыруны оештыру өчен җаваплы;

– әлеге Нигезләмәдә каралган локаль актлар кабул итүне тәэмин итә;

– мәгариф учреждениесе хезмәткәрләре арасыннан мәгариф учреждениесендә туклануны оештыру өчен җаваплы кеше билгеләп куя;

– сыйныфларда ата-аналар җыелышлары, гомуми ата-аналар җыелышы, шулай ук мәктәп советы утырышларында укучыларны тукландыруны оештыру мәсьәләләрен карауны тәэмин итә.

4.3. Азык-төлек продуктлары белән тәэмин итүче предприятие:

– азык-төлек продуктларын үз вакытында китерү;
– китерелә торган продукциянең сыйфатлы булуы;
– санитар кагыйдәләрнең үтәлешенә һәм санитария-эпидемияләргә каршы (профилактик) чаралар үтәлешенә производство контролен оештыру;
– әлеге Нигезләмәдә һәм учреждение белән төзелгән килешүдә каралган бүтән йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итү өчен җаваплылык тота.

4.4. Ел саен директор боерыгы белән туклануны оештыру өчен җаваплы итеп билгеләнгән зат:
– бушлай туклanучы укучылар исемлегендәге үзгәрешләр турында үз вакытында мәгълүмат бирергә;
– көн саен туклanучылар санын ачыклау өчен учреждение укучыларын исәпкә алырга;
– менюның стендта булуын тикшерергә;
– әзер ризыкның менюга туры килүен тикшерергә;
– меню буенча чыгу нормасының порция авырлыгына туры килүен тикшерергә;
– сыйныф җитәкчеләренең эшчәнлеген координацияләргә һәм контрольдә тотарга;
– укучыларның туклануына акчаны исәпләү өчен бухгалтериягә укучыларның исемлекләрен тапшырырга;
– укучыларның ашханәгә йөрешен исәпкә алырга, барлык укучыларны ризык белән тәэмин итүне, сыйныфларда укучылар тарафыннан фактта алынган төшке ашлар санын көн саен исәпкә алуның тәртибен контрольдә тотарга;
– мәгариф учреждениесендә туклану культурасын формалаштыру буенча эшне координацияләргә;
– мәктәптә туклануның сыйфаты белән канәгать булу мониторингын тормышка ашырырга;
– туклануны оештыруны яхшырту буенча тәкъдимнәр кертергә бурычлы.

4.5. Мәгариф учреждениесенең сыйныф җитәкчеләре:
– учреждениедә туклануны оештыру турында ата-аналарга (законлы вәкилләргә) мәгълүмат җиткерәләр;
– 48 сәгать эчендә мәктәп ашханәсенә уку көненә туклануны оештыру өчен гариза тапшыралар;
– көн саен 8: 30 дан да соңга калмыйча бирелгән гаризаны төгәлләштерәләр;
– укучылар тарафыннан алынган иртәнге һәм төшке ашларны көндәлек исәпкә алу табелен алып баралар;
– үз компетенцияләре өлешендә мәктәп туклануын оештыру мониторингын гамәлгә ашыралар;
– тәрбия эше планында укучыларның сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга, баланслы һәм рациональ туклануга булган ихтыяҗны формалаштыруга юнәлдерелгән чараларны карыйлар, ата-аналар җыелышлары

барышында даими рәвештә фикер алышуга укучыларның тулысынча кайнар ризык белән тәэмин ителү мәсьәләләрен чыгаралар;

– педагогик совет утырышларында, директор каршындагы киңәшмәләрдә туклануны яхшырту буенча тәкъдимнәр әзерлиләр.

4.6. Укучыларның әти-әниләре (законлы вәкилләре):

– баланың туклануы өчен түләүне үз вакытында, ай саен, 10 числодан да соңга калмыйча кертәләр;

– сыйныф җитәкчесенә үз вакытында баланың авыруы яисә аның гомуми белем бирү учреждениесендә вакытлыча булмавы турында, ул фактта булмаган чорда аны тукланудан төшерү өчен хәбәр итәргә, шулай ук медицина хезмәткәрен һәм сыйныф җитәкчесен балада азык-төлек продуктларына булган аллергик реакцияләр турында кисәтергә тиеш;

– үз балалары белән сәламәт яшәү рәвеше һәм дөрес туклану күнекмәләрен үстерү буенча аңлату эшләре алып баралар;

– укучыларның туклануын оештыруны яхшырту буенча тәкъдимнәр кертергә хокуклы;

– якынча һәм көндәлек меню белән, укучыларны ашатуны оештыруга акча исәп-хисаплары белән танышырга хокуклы.

4.7. Мәктәп ашханәсендә, күренә торган урынга, бракераж комиссиясе, иҗтимагый комиссия составы, меню, ризык кабул итү вакыты, туклану культурасы буенча материаллар, фикерләр һәм тәкъдимнәр китабы күрсәтелгән мәгълүмат стенды эленә.